**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 25 декабрендәге 5354 номерлы карары**

**Казан шәһәре Вахитов районының Һади Атласи урамында**
**ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарга 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитут характеристикасы:

- йогынты ясала торган өлкә мәйданы – 64 кв.м;

- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры – 16:50:011123:209;

- урнашу урыны: Казан шәһәре, Вахитов районы, Һади Атласи урамы;

- билгеләү максаты: электр белән тәэмин итүне (технологик тоташтыруны) оештыру өчен;

- билгеләү вакыты: 10 ел;

1.2. гариза бирүче: «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте;

1.3. билгеләү өчен нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы «Электр челтәре хуҗалыгы объектларының сак зоналарын һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым шартларын билгеләү тәртибе турында»гы карары, Казан шәһәре Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округы Генераль планы, электр челтәрләренә технологик тоташтыруны гамәлгә ашыру турында 2020 елның 7 декабрендәге 12020/КЭС/Т909 номерлы шартнамә.

2. Сервитутны гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яки сизелерлек кыенлашачак вакыт әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут вакытына туры килә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут өчен түләү Россия Федерациясе Җир кодексының 39.46 статьясындагы 2, 3, 4, 5, 7 һәм 8 пунктлар нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарга 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт

теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

5. Әлеге карарга 2 номерлы кушымтадан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

7. «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенә тәкъдим итәргә:

7.1. әлеге карарның 1.1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлегенең хокук иясе белән ачык сервитутны гамәлгә ашыру турында килешү төзергә;

7.2. әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлеген, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яки агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү эшләре тәмамланганнан соң яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктлар белән каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң өч айдан да соңга калмыйча, аңардан рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә;

7.3. җир кишәрлегеннән файдаланганда Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2017 елның 13 мартындагы 218од номерлы «Казан шәһәренең төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлеге территориясе чикләрендә территория чикләрен, саклау предметын һәм шәһәр төзелеше регламентларына таләпләрне раслау турында»гы әмере нигезендә чикләүләрне үтәргә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 25 декабрендәге
5354 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

## Казан шәһәре Вахитов районының Һади Атласи урамында ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре




Масштаб 1:250
Координаталар системасы: МСК-16

| Шартлы билгеләр: | |
|---|---|
| | Ачык сервитутлар (Проектлана торган) |
| | Ясала торган җир кишәрлекләре чикләре (гамәлдәге) |
| | Җир кишәрлекләре |
| | Кадастр кварталлары |
| 16:50:011123 | кадастр кварталы |
| 16:50:011123:209 | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |

______________________________